**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 июнь № 410

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксаларны раслау турында» 2007 ел, 25 май, 200 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының эчке сулыкларында су биология ресурсларын саклауны интенсивлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксаларны раслау турында» 2007 ел, 25 май, 200 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 июнь, 451 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә йөкләргә»;

бу карар белән расланган Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксаларны яңа редакциядә бәян итәргә (декарарга теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 25 май, 200 нче карары белән расланган Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксаларга үзгәреш кертү турында» 2013 ел, 29 июнь, 451 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 25 май, 200 нче карары белән расланган Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксаларга үзгәреш кертү турында» 2015 ел, 1 июль, 480 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\410.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 25 май, 200 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 июнь, 410 нчы карары редакциясендә)

Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксалар

| Су биология ресурслары төрләре | Су биология ресурслары төренең 1 экземплярын юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару өчен түләү күләме, сум |
|---|---|
| Густера, синец, аккүзчек, көмеш табан балык, алтын табан балык, кара балык, чабак, кызылканат, кәлчәк, бәртәс, берш, җумба | 200 |
| Головешка-ротан, гади кыртыш, этләч, йомры чабак, верховка, ләрге балык (гади), ташбаш, җилембалык, щиповка, энә-балык, тюлька (вак балык) | 100 |

Искәрмәләр:

1. Җәрәхәтләгән өчен, әгәр ул су биология ресурсларының әлеге төрләренең үлеменә китермәгән булса, тиешле төрнең бер экземпляры өчен таксаның 50 проценты түләттерелә.

2. Әлеге төрләрдәге су биология ресурсларының һәр ана балыгын уылдыгы белән юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару өчен зыян тиешле төрнең экземплярына таксаның ике тапкырга арттырылган күләмендә исәпләнә.

3. Төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыклары территориясендә (акваториясендә) әлеге төрләрдәге су биология ресурсларын юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару өчен зыян – тиешле төрнең экземплярына таксаның өч тапкырга арттырылган күләмендә, төбәк әһәмиятендәге башка махсус саклана торган табигать территорияләрендә ике тапкырга арттырылган күләмендә исәпләнә.

4. Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Идел-Каспий балык хуҗалыгы бассейны өчен балык тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2014 ел, 18 ноябрь, 453 нче боерыгы белән расланган су биология ресурсларын тоту тыелган чорларда әлеге төрләрдәге су биология ресурсларын юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару өчен зыян тиешле төрнең экземплярына таксаның ике тапкырга арттырылган күләмендә исәпләнә.